СОВЕТ МАЛОЛЫЗИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
БАЛТАСИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
КЕЧЕ ЛЫЗИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«1» ноябрь 2023 ел № 89

Татарстан Республикасы Балтач Муниципаль районының Кече Лызи авыл җирлегендә гавами тыңлаулар (иҗтимагый фикер алышулар) уздыру тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

28.09.2023 елның №02-08-01-2023/Прдп 308-23-20920011номерлы протест нигезендә “Гавами тынлаулар (җәмәгать тикшерүләре) үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау турында” карарга, “Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында” һәм “России Федерациясендә тимер юл транспорты турында” Федераль Законның 16 статьясындагы 2 пунктының икенче абзацының үз көчен югалтуын тану хакында” 29.12.2022 елның 612 номерлы Федераль Закон нигезендә Кече Лызи авыл җирлеге Советы карар бирде:

1.Кече Лызи авыл җирлеге Советының 28.05.2020 елның 232 номерлы карары белән расланган (29.06.2022 елның 50 номерлы карарындагы үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән) гавами тыңлаулар (иҗтимагый фикер алышулар) уздыру тәртибе турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1.Нигезләмәнең 3 статьясындагы 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 4 нче пунктча өстәргә:

4) генераль планнар проекты, җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проекты, территорияне планлаштыру проектлары, территорияне ызанлау проекты, территорияне төзекләндерү кагыйдәләре проекты, күрсәтелгән документларның берсенә үзгәрешләр кертүне күздә тоткан проектлар, җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турындагы карарлар, рөхсәт ителгән төзелешнең иң чик параметрларыннан тайпылуга, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүгә рөхсәт бирү турындагы карарлар проектлары, моңа Шәһәр төзелеше Кодексында һәм башка федераль законнарда каралган очраклар керми.

1.2.Нигезләмәгә түбәндәге эчтәлекле статья өстәргә:

13 статья. Муниципаль берәмлекләрне территориаль планлаштыру документлары проектлары буенча җәмәгать фикер алышуларын, гавами тынлауларны карау үзенчәлекләре.

Генераль планнар проектларына, җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектларына, территорияне планлаштыру проектларына, территорияне ызанлау проектларына, территорияләрне төзекләндерү кагыйдәләре проектларына кагылышлы мәсьәләләр, күрсәтелгән документларның берсенә, җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлыча рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында карарлар проектларына үзгәрешләр кертүне күз алдында тоткан проектлар, рөхсәт ителгән төзелешнең чикле параметрларыннан читкә тайпылуга, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүгә, җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан рөхсәт ителгән файдалануның бер төрен үзгәртү мәсьәләләренә, җирләрдән файдалануның расланган кагыйдәләре булмаганда, мондый файдалануның башка төренә үзгәрешләр кертү турындагы карарлар проектлары шулай ук төзелеш эшләре, Россия Федерациясе шәһәр төзелеше кодексында билгеләнгән нигезләмәләрне исәпкә алып, иҗтимагый фикер алышуларга чыгарылырга мөмкин.

Җирлекләрнең генераль планнары проектлары буенча иҗтимагый фикер алышуларны, гавами тынлауларны оештыру һәм уздыру үзенчәлекләре Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 28 маддәсендә китерелгән.

Генераль план проекты буенча һәм җирлекләрнең генераль планнарына үзгәрешләр кертүне күздә тоткан проектлар буенча иҗтимагый фикер алышулар яисә гавами тынлаулар мәҗбүри тәртиптә үткәрелә (алга таба – иҗтимагый фикер алышулар яисә гавами тыңлаулар).

Иҗтимагый фикер алышулар яисә гавами тыңлауларда катнашучыларны җәмәгать фикер алышуларында яисә гавами тынлауларда катнашу өчен бертигез мөмкинлекләр белән тәэмин итү максатларында җәмәгать фикер алышулары яисә гавами тыңлаулар уздырганда җирлек территориясе өлешләргә бүленергә мөмкин.

Җәмәгать фикер алышуларын яки Җәмәгать тыңлауларын үткәрү вакыты җирлек халкына аларны үткәрү турында хәбәр ителгәннән алып җәмәгать фикер алышулары яки җәмәгать тыңлаулары нәтиҗәләре турында нәтиҗә басылган көнгә кадәр җирлек Уставы яки җирлек Советының норматив хокукый акты белән билгеләнә һәм бер айдан да ким булмаска тиеш.

2. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чykканнан соң үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының рәсми baltasi.tatarstan.ru. сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны төзекләндерү, төзелеш, хокукларны яклау һәм җәмәгать тәртибен саклау буенча даими комиссиягә йөкләргә .

Рече Лызи авыл җирлеге башлыгы А.С.Исмагилов